| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕКУРГУЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАРАУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| РЕШЕНИЕ | с.Большие | КАРАР |
| 25.11.2024 | Кургузи | №187 |

Зеленодольск муниципаль районының «Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы түләү ставкалары, тәртибе турында»гы 2019 елның 1 ноябрендәге 244 номерлы Карауҗа авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Карауҗа авыл җирлеге Советының 12.11.2020 №12, 17.09.2021 № 55, 29.05.2023 №131 һәм 26.10.2023 №143 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон (2024 елның 29 октябрендәге редакциядә), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карауҗа авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Зеленодольск муниципаль районының «Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы түләү ставкалары, тәртибе турында»гы 2019 елның 1 ноябрендәге 244 номерлы Карауҗа авыл җирлеге Советы карарына (Карауҗа авыл җирлеге Советының 12.11.2020 №12, 17.09.2021 № 55, 29.05.2023 №131 һәм 26.10.2023 №143 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.1) 0,3% торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата, әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, моңа индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләренең һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләренә карата»;

1.2. 1.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2) 0,3% шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый

торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм аерым Россия Федерациясе актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3%», әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләренә карата».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Карауҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Зур Карауҗа авылы, Күпер урамы, 23 йорт(мәдәният йорты бинасы), Зур Күлбаш авылы, Тау асты урамы, 26 йорт (мәдәният йорты бинасы) адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Карауҗа авыл җирлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

**Башлык урынбасары** **И.С. Камалиев**